ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 244 от «15» 08 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының хисап чорында «Балалар һәм яшьләр сәләтен һәм талантын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 21 июлендәге «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары турында» 474 номерлы, 2021 елның 4 февралендәге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 68 номерлы указлары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

карар бирә:

1. Әлеге карарга теркәлеп килүче Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының хисап чорында «Балалар һәм яшьләр сәләтен һәм талантын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын расларга.

2. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә секторына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокук порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р.Хуҗәҗановка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов

0000011537

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы
башкарма комитетының
«15» 08 2022 ел, №294 карарына
Кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының хисап чорында «Балалар һәм яшьләр сәләтен һәм талантын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Регламентны җайга салу предметы.

Әлеге Мамадыш муниципаль районының хисап чорында «Балалар һәм яшьләр сәләтен һәм талантын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 21 июлендәге «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсеше милли максатлары турында» 474 номерлы, 2021 елның 4 февралендәге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 68 номерлы указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 542 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы турында» 920 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 18 апрелендәге «Контроль» модуленең бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасына үзгәрешләр кертү турында» 361 номерлы карары нигезендә эшләнгән һәм хисап чорында «Балалар һәм яшьләр сәләтен һәм талантын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча җирле үзидарә органы эшчәнлеген билгели (алга таба - декомпозацияләнгән күрсәткеч):

2015 елдан хисап елы тәмамланганчы югары сәләте һәм таланты ачыкланган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр өлеше, процент;

хисап елында төрле формаларда дәүләт ярдәме алган һәм югары сәләтен күрсәткән 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр өлеше, процент.

Мамадыш муниципаль районында декомпозия күрсәткечләрен җыйган һәм мониторинглаган өчен җаваплылык үзәге булып «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ (алга таба - мәгариф бүлеге) тора.

## 1.2. Белешмә мәгълүмат.

Әлеге Мамадыш муниципаль районының хисап чорында «Балалар һәм яшьләр сәләтен һәм талантын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты максатлары өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 542 номерлы карарындагы күрсәткечне исәпләү методикасында билгеләнгән терминнар кулланыла.

## 2. Исәпләү стандарты, җыю тәртибе, мәгълүмат бирү тәртибе

Исәп-хисап стандарты, мәгълүматлар җыю һәм бирү тәртибе декомпозицияләнгән күрсәткечләрне исәпләп чыгару өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләрнең гомуми саны, кеше;

2015 елдан башлап Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән олимпиадаларда һәм башка конкурс чараларында җиңүче булган һәм (яисә) теркәлгән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре булган, һәм (яисә) фәнни халыкара яисә бөтенроссия басмаларында, шул исәптән халыкара мәгълүмат базаларында индексацияләнгән басмаларда (Web of Science, Scopus h.б.) мәкалә авторлары булган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны, кеше (алга таба - 2015 елдан башлап югары сәләте һәм таланты ачыкланган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны);

хисап елында төрле формаларда дәүләт ярдәмен алган югары сәләте һәм таланты ачыкланган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны, кеше.

Мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре югарыда күрсәтелгән белешмәләр буенча хисап чорында белешмәләр җыюны гамәлгә ашыра:

"Ачык Татарстан" системасы мәгълүматлары нигезендә 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балаларның һәм яшьләрнең гомуми саны;

әлеге муниципаль районда (шәһәр округында) урнашкан гомуми белем бирү оешмаларыннан сәләтле балалар турында мәгълүматлар базасы нигезендә 2015 елдан югары сәләте һәм таланты ачыкланган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны.

Мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре мәгълүматларны электрон формада җыю формасын җибәрә, анда мәгариф оешмасы вәкилләре укучыларның уңышлары турында мәгълүмат кертә:

1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән конкурс чараларындагы призлы урыннар;

2. интеллектуаль эшчәнлекнең теркәлгән нәтиҗәләре;

3. фәнни халыкара яисә бөтенроссия басмаларында, шул исәптән халыкара мәгълүмат базаларында индексацияләнә торган басмаларда (Web of Science, Scopus һ.б.) мәкаләләр бастыру.

Югары сәләтен күрсәткән балалар турында мәгълүматлар базасы бөтен муниципаль район (шәһәр округы) буенча җыелма формада яшь кешеләрне һәм аларның казанышларын исәпкә алу, шулай ук алынган ярдәм чараларын теркәү өчен электрон формада саклана.

Мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре югары сәләтен күрсәткән балалар турында мәгълүматлар базасына кертелгән узган елгы 11 нче сыйныфны тәмамлаучылар алган дәүләт ярдәме чаралары турында мәгълүмат соратып алу юлы белән җыйган мәгълүмат нигезендә 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге, югары сәләт күрсәткән һәм хисап елында төрле формаларда дәүләт ярдәме алган балалар һәм яшьләр саны Мониторингка тиешле дәүләт ярдәме чаралары ел саен, 2023 елдан башлап, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

Мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре муниципаль район (шәһәр округы) буенча җыелма мәгълүматны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Казан ачык талантлар университеты 2.0» АНО mon.sbor@tatar.ru һәм info@utalents.ru электрон почтасы адресына мәгълүмат копиясе белән Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында рәсми хат белән җибәрә.

2023 елдан сәләтле балалар турында мәгълүматлар базасын җыю "Казан ачык талантлар университеты 2.0" порталы аша гамәлгә ашырылачак.

**2. Мәгълүматлар бирү составы, вакыты һәм формасы**

a: Хисап елында югары сәләтен күрсәткән һәм төрле формаларда дәүләт ярдәме алган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны, кеше;

b.

| № т/б | Оешма исеме | Үлчәү берәмлеге (кеше) | Мәгълүмат бирү вакыты квартал саен хисаптан соң килүче айның 1 числосына кадәр | a. Хисап елында югары сәләтен күрсәткән һәм төрле формаларда дәүләт ярдәме алган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

c. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән олимпиадаларда һәм башка конкурс чараларында җиңүче булган һәм (яисә) теркәлгән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре булган, һәм (яисә) фәнни халыкара яисә бөтенроссия басмаларында, шул исәптән халыкара мәгълүмат базаларында индексацияләнгән басмаларда (Web of Science, Scopus h.б.) мәкалә авторлары булган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны, кеше

| № п/п | Оешма исеме | Үлчәү берәмлеге (кеше) | Мәгълүмат бирү вакыты квартал саен хисаптан соң килүче айның 1 числосына кадәр | Хисап елында 2015 елдан югары сәләте һәм таланты ачыкланган 7 яшьтән 35 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр саны. |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |